**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 24 декабрь № 968

г. Казань

2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын тотуга аерым чыгымнар формалаштыру нормативларын билгеләү турында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарын тотуга бюджет акчасын нәтиҗәле сарыф итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2016 елга Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлеген төзегәндә кулланыла торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының элемтә хезмәтләре күрсәтү чыгымнары нормативын бер хезмәткәргә бер елга иң күбе 9,5 мең сум күләмендә; агымдагы башка чыгымнар (коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә, элемтә хезмәтләре күрсәтүгә, мөлкәттән файдаланган өчен аренда түләвенә, ведомствога карамаган сак хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнардан тыш) нормативын бер хезмәткәргә аена иң күбе 6,5 мең сум күләмендә дип;

чыгымнарны хисаплап чыгару максатчан характердагы өстәмә бюджет ассигнованиеләрен исәпкә алмыйча хезмәткәрләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән иң чик саныннан чыгып гамәлгә ашырыла дип.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын тотуга аерым чыгымнар формалаштыру нормативларын билгеләү турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1049 нчы карары 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\968.docx